**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.03.2017 № 194

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 20 апрелендә теркәлде, № 3898

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 19.11.2014 ел, № 643 боерыгы белән расланган, Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибен раслау турында” 17.12.2004 ел, №542 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибен раслау турында нигезләмәгә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 19.11.2014 ел, № 643 боерыгы белән расланган, Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | 1. Бу Регламентка №1 кушымта нигезендәге форма буенча, банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган лицевой счетның реквизитларын күрсәтеп (балага пособиене банк яки башка кредит оешмасы аша алганда), балага пособие билгеләү турында гариза.<br>2. Баланың (балалар) тууын Татарстан Республикасыннан читтә дәүләт теркәвенә алу очракларында баланың (балалар) туу турында таныклыгы күчермәсе.<br>3. Дәүләт хезмәте алучының гариза тапшыру аена кадәрге соңгы алты ай эчендәге керемнәре (мәгълүматлары Россия Федерациясе Пенсия фондында булган түләүләрдән һәм Россия Эчке эшләр министрлыгы түли торган түләүләрдән тыш) турында документлар, шул исәптән:<br>а) “Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында” 24 декабрь, 2007 ел, № 922 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләүдә исәпкә алына торган хезмәткә түләү системасында күздә тотылган барлык түләүләр;<br>б) хезмәт законында күздә тотылган очракларда сакланып калына торган уртача хезмәт хакы;<br>в) дәүләти яки иҗтимагый бурычларны үтәү вакытында дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнелә торган компенсация;<br>г) эштән киткәндә түләнелә торган китү пособиесе, отставкага киткәндә түләнелә торган компенсация, оешма бетерелүгә, хезмәткәрләрнең саны яки штаты кимүгә бәйле рәвештә эштән киткәндә эшкә урнашу чорына сакланып калына торган хезмәт хакы;<br>д) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүдән керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, шул исәптән юридик зат булдырмыйча гына хуҗалык итү эшчәнлеге алып бару нәтиҗәсендә алынган керемнәр; | Нигезләмәнең 3.6, 3.7, 3.8, 3.9, 3.10 п.; Тәртипнең 2.1 п. |

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 29.03.2017 ел, № 194 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 19.11.2014 ел, № 643 боерыгы белән расланган, Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.2. Дәүләт хезмәте алучылар булып җан башына туры килә торган кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артып китмәгән гаиләләрдән, 16 яшькә кадәрге (гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга – укуларын тәмамлаганчы, әмма гомуми белем бирү оешмасын тәмамлаганнан соң күп дигәндә ике айга һәм бала 18 яшькә җиткәнче генә), үзләре тудырган, уллыкка (кызлыкка) алынган, опекага (попечительлек) алынган балалары белән даими яшәү урыны яки вакытлыча булу урыны буенча бергә яшәүче ата-аналарның берсе (законлы вәкил) тора.”;

1.5 пунктта:

өченче һәм сигезенче абзацларны төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 17.12.2004 ел, № 542 карар белән расланган, “Балага айлык пособие билгеләнгәндә гаиләнең җан башына туры килә торган керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 10.09.2016 ел, № 625 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, “Балага айлык пособие билгеләнгәндә гаиләнең җан башына туры килә торган керемен исәпләү тәртибе (алга таба - Тәртип) нигезендә (Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматлар рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru; кертелгән үзгәрешләрдән чыгып)”;

| | | | |
|---|---|---|---|
| | е) отставкага чыккан судьяларга бөтен гомере буе ай саен бирелә торган акча;<br>ж) хәрби хезмәткәрләргә, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-башкару системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм башка хокук саклау органнары хезмәткәрләренә хезмәт хакы, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән даими характердагы акчалата түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин итү;<br>з) Россия Федерациясе Гражданлык кодексы нигезендә төзелә торган килешүләр буенча эшләргә түләү;<br>и) социаль түләүләр:<br>һөнәри уку йортларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча белем алучы аспирантларга һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына, дини белем бирүче оешмаларда белем алучыларга түләнелә торган стипендия һәм матди ярдәм;<br>хезмәт килешүе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торып, 3 яшькә кадәрге баланы карау ялындагы гражданнарга айлык компенсация түләүләре;<br>ирләре белән бергә яшәү чорында белгечлеге буенча эшкә урнаша алмау сәбәпле эшләмәскә мәҗбүр булган һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылганда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары ирләренең хәрби хезмәт урынындагы яшәү шартларына бәйле рәвештә балаларының сәламәтлеге какшау аркасында эшләмәскә мәҗбүр булган чорда, медицина оешмасы белешмәсе нигезендә балалары читләр каравына мохтаҗ булганда, контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең хатыннарына айлык пособие;<br>хатын-кызларга эшкә урнашу мөмкинлеге булмаган ерактагы гарнизоннарда һәм урыннарда Россия Федерациясе эчке эшләр органнары һәм җинаять-башкару системалары учреждениеләренең рядовой һәм җитәкче | |

| | | |
|---|---|---|
| | составтагы затларының эшләмәүче хатыннарына айлык компенсация түләве;<br>медицина күрсәтмәләре буенча бирелгән академия ялы чорында студентларга, аспирантларга һәм докторантларга бирелә торган компенсация түләүләре;<br>хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре балаларына айлык пособие;<br>хәрби хезмәткәр яки хәрби җыеннарга чакырылган гражданин хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән) яисә хәрби җәрәхәт аркасында үлгән очракта, гаиләсенең һәр әгъзасына түләнелә торган айлык акчалата компенсация;<br>к) гаилә (аның аерым әгъзалары) милкендәге мөлкәттән керемнәр, аларга керә:<br>күчемсез милекне (җир кишәрлекләрен, йортлар, фатирлар, дачалар, гаражлар), транспортны һәм башка механик средстволарны, продуктларны эшкәртү һәм саклау средстволарын сату һәм арендага (найм) биреп торудан керемнәр;<br>шәхси ярдәмче хуҗалыкта үстерелгән-алынган җиләк-җимеш һәм продукция сатудан керемнәр;<br>л) керемнәрнең башка төрләре, аларга керә:<br>хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, җинаять-башкару системасы учреждениеләре һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан, башка хокук саклау хезмәте органнарыннан киткәндә бер тапкыр түләнелә торган пособие;<br>эш бирүчеләр тарафыннан үз хезмәткәрләренә, шул исәптән инвалидлык буенча яки яше җитеп пенсиягә чыккан элекке хезмәткәрләренә күрсәтелә торган матди ярдәм;<br>авторлык хокукы һәм чиктәш хокуклар турында Россия Федерациясе законы нигезендә бирелә торган автор гонорарлары, шул исәптән мираска калдырылган авторлык килешүләре буенча;<br>акцияләр буенча керемнәр һәм оешма милке белән идарә итүдә катнашудан башка керемнәр; | |

| | | |
|---|---|---|
| | гаилә әгъзалары тарафыннан алына торган алиментлар;<br>банк кертемнәре буенча процентлар;<br>мираска калдырылган һәм бүләк ителгән акча средстволары. | |
| | 4. Уналты яшьтән зуррак баланың (балалар) Россия Федерациясенең башка субъектлары территорияләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмә.<br>5. Гариза бирүченең гаиләсе әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслаган документлар (ирекле рәвештә төзелгән):<br>үзләренең персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыкның булуын;<br>персональ мәгълүматларны органга яки оешмага тапшырганда гариза бирүченең алар исеменнән эш итүгә вәкаләтен.<br>Ялгыз бала анасына айлык пособие алу өчен мөрәҗәгать иткән зат таныклыкка баланың әтисе турында мәгълүматлар кертүгә нигез турында ЗАГС органнарыннан өстәмә рәвештә белешмә тапшыра.<br>Әти-әнисе алиментлар түләүдән читләшкәндә яки алиментлар түләтү мөмкин булмаганда, балага айлык пособие алу өчен мөрәҗәгать иткән зат түбәндәге документларның берсен өстәмә рәвештә тапшыра:<br>иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениедә җәза үтәүгә, кулга алынуда, мәҗбүри дәвалануда булуга бәйле рәвештә алиментлар түләтү мөмкин булмаганда, бурычлының хезмәт хакына ия булмавы турында учреждениедән белешмә;<br>алиментлар түләүдән читләшүенә бәйле рәвештә бурычлының эзләнелүе турында Федераль суд приставлары хезмәтеннән карар;<br>җинаять кылган өчен ата-аналарны җинаять җаваплылыгына тарту турында эчке эшләр органнарыннан белешмә. | |
| | Чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрнең баласына айлык пособие алу өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөрәҗәгать иткән зат баланың әтисен хәрби хезмәткә чакыру турында хәрби комиссариаттан белешмә яки баланың әтисенең укуы турында хәрби һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениесеннән белешмә өстәмә рәвештә тапшырырга тиеш.<br>Законлы вәкилләр (закон нигезендә күздә тотылган очракларда) яки дәүләт хезмәте алучыларның вәкаләтлеләре дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документлар күчермәләрен тапшыра.<br>Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен раслаучы документ күрсәтә.<br>Гариза бирүче документларны һәм белешмәләрне турыдан-туры тиешле оешмалардан ала, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә.<br>Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә шәхсән яки почта аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Россия Федерациясе законы нигезендә расланмаган очракта, документлар күчермәләре төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа кушып бирелә торган документлар күчермәләре (шәхесне раслаучы документ күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законы нигезендә расланылырга тиеш.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Электрон рәвештәге бланк Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган.<br>Гариза шулай ук Үзәк бүлегендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырылырга мөмкин. Гариза бирүче мондый гаризага имзаны электрон җайланма куллану нигезендә имза сала.<br>Гариза бирүче тарафыннан гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар гомуми мөмкинлекле мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән "Интернет" мәгълүмат– | |

| | | |
|---|---|---|
| | телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яисә Татарстан Республикасының Электрон Хөкүмәт инфоматлары аша квалификацияле көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына:

баланың (балалар) туу актын Татарстан Республикасы территориясендә (ЗАГС органнарында) теркәүгә алган очракларда дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар;

эшсез гражданнарга эшсезлек буенча пособие түләү, матди ярдәм һәм башка түләүләр турында, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнелә торган стипендия һәм матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль ярдәмгә аеручa мохтаҗ гражданнарга вакытлыча эшләрдә катнашу чорында түләүләр, шулай ук 14тән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга вакытлыча эшләрдә катнашу чорында (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәтләре органнарында) түләүләр турында мәгълүматлар;

түбәндәге түләүләрнең күләмнәре турында мәгълүматлар: Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан (Россия Федерациясе Пенсия фондында) бирелә торган пенсияләрнең, компенсация түләүләре һәм пенсионерларга айлык өстәмә матди тәэминатның:

эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән ( Россия Федерациясе Пенсия фондына) түләүләр һәм башка акча суммасы турында;

пенсия алу, билгеләү, пенсия алмау һәм түләүләрне туктату турында (Россия Эчке эшләр министрлыгы);

социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында) түләнелә торган йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие күләмнәре турында мәгълүматлар;

йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә учетка баскан хатын-кызларга социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында) бер тапкыр түләнелә торган пособие күләмнәре турында мәгълүматлар;

социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү

фондының территориаль органнары тарафыннан (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында) түләнелә торган бала карау буенча айлык пособие күләмнәре турында мәгълүматлар;

социаль яклау органнары тарафыннан (социаль яклау органнарында) түләнелә торган, бу Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән социаль түләүләрнең барлык төрләре буенча өстәмәләр һәм өстәп түләүләр күләмнәре турында мәгълүматлар;

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнеп, социаль яклау органнары тарафыннан (социаль яклау органнарында) түләнелә торган башка социаль түләүләрнең күләмнәре турында мәгълүматлар;

алучының гаиләсе составы турында мәгълүматлар (вәкаләтле органнарда);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) тарафыннан бала карауга акча средстволары алу турында мәгълүматлар (җирле үзидарә органнарында);

үзенә сыендыручы гаиләгә бала тапшыру һәм үз гаиләсенә сыендырган ата-аналарга тиешле акча суммалары турында мәгълүматлар (җирле үзидарә органнарында);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукын чикләү турында мәгълүматлар (җирле үзидарә органнарында);

медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминиятләштерү очрагының килеп чыгуының аянычлы нәтиҗәсе булып һөнәри эшенә сәләтен югалту торган иминиятләштерелгән гражданнарга яки иминиятләштерү очрагының килеп чыгуының аянычлы нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның үлеме торганда, айлык иминиятләштерү түләүләре алуга хокуклы затларга җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча айлык иминиятләштерү түләүләре турында мәгълүматлар (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында) ;

уналты яшьтән зуррак баланың (балалар) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында укуы турында мәгълүматлар (гомуми белем бирү оешмасыннан).

Гариза бирүче Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасының Электрон Хөкүмәт инфоматлары аша мөрәҗәгать иткәндә, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша гариза бирүченең паспортының чынлыгын раслау турында мәгълүматлар өстәмә рәвештә тапшырыла (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

Әлеге документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Гариза бирүче тапшыруга хокуклы документларны алу һәм тапшыру

тәртибе бу Регламентның 2.5. пунктында билгеләнгән.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтеп үтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тора алмый.

Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасының 2.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос тапшырганда һәм мондый хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.";

3 бүлекнең 3.4 пунктындагы 3.4.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.4.2. Үзәк бүлегендә балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда. Үзәк бүлеге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә түбәндәге мәгълүматларны тапшыру турында запрослар җибәрә:

Татарстан Республикасы территориясендә туу актын теркәү очрагында, 2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, - ЗАГС органнарына;

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечитель) баланы карап тотуга акча средстволары алуы турында – җирле үзидарә органнарына;

үзенә сыендыручы гаиләгә бала тапшыру һәм үз гаиләсенә сыендырган ата-аналарга тиешле акча суммалары турында, - җирле үзидарә органнарына;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукын чикләү турында, - җирле үзидарә органнарына;

медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминиятләштерү очрагының килеп чыгуының аянычлы нәтиҗәсе булып һөнәри эшенә сәләтен югалту торган иминиятләштерелгән гражданнарга яки иминиятләштерү очрагының килеп чыгуының аянычлы нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның үлеме торганда, айлык иминиятләштерү түләүләре алуга хокуклы затларга җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча айлык иминиятләштерү түләүләре турында, - Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарына;

вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособие, йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә учетка баскан хатын-кызларга йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие, шулай ук бер тапкыр түләнелә торган пособие күләмнәре турында - Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органында:

бала карау буенча айлык пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе

Социаль иминиятләштерүгә фондының территориаль органына;

эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка акча суммасы турында - Россия Федерациясе Пенсия фондына;

пенсия алу, билгеләү, пенсия алмау һәм түләүләрне туктату турында - Россия Эчке эшләр министрлыгына;

гариза Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, гариза бирүченең паспортының чынлыгын раслау турында - Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына;

уналты яшьтән зуррак баланың (балалар) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында укуы турында - гомуми белем бирү оешмасына.";

Регламентка кушымтаны (белешмә) түбәндәге редакциялә бәян итәргә:

"Балага айлык пособие билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына) кушымта
(белешмә)

**Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

1. "Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге" дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. "Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге" дәүләт казна учреждениесе бүлекләре

| п/п | Бүлек атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|---|
| 1 | Республика матди ярдәм үзәгенең "Чаллы" шәһәр округындагы №1 бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең "Чаллы" шәһәр округындагы №2 бүлеге | (8552)<br>38-37-30,<br>39-88-88,<br>47-49-21,<br>47-46-54<br>70-43-09,<br>71-80-35, | 423823, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Кояшлы бульвар, 6 й., №1 подъезд;<br>423823, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Кояшлы бульвар, 6 й., №2 подъезд.<br>chl.1@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 71-49-39,<br>71-80-33 | 423850, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Гидротөзүчеләр ур.,, 14 й.<br>chl.2@tatar.ru |
| 2 | Республика матди ярдәм үзәгенең Әгерҗе муниципаль районындагы №2 бүлеге | (85551)<br>2-10-66,<br>2-29-51,<br>2-42-33,<br>2-28-32 | 422230, Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Карл Маркс ур., 11А й.<br>agr.2@tatar.ru |
| 3 | Республика матди ярдәм үзәгенең Азнакай муниципаль районындагы №3 бүлеге | (85592)<br>7-25-88,<br>7-13-99,<br>7-25-93,<br>7-25-88 | 423330 Татарстан Республикасы, Азнакай ш., Болгар ур., 9/2 й.<br>azn.3@tatar.ru |
| 4 | Республика матди ярдәм үзәгенең Аксубай муниципаль районындагы №4 бүлеге | (84344)<br>2-92-73,<br>2-92-76,<br>2-92-75 | 423060, Татарстан Республикасы, Аксубай ш.т.б., Мазилин ур., 2 й.<br>aks.4@tatar.ru |
| 5 | Республика матди ярдәм үзәгенең Актаныш муниципаль районындагы №5 бүлеге | (85552)<br>3-16-01,<br>3-22-97,<br>3-22-96 | 423740, Татарстан Республикасы, Актаныш ав., Юбилей ур., 45 й.<br>akt.5@tatar.ru |
| 6 | Республика матди ярдәм үзәгенең Алексеевск муниципаль районындагы №6 бүлеге | (84341)<br>2-37-73,<br>2-53-01,<br>2-32-75 | 422900, Татарстан Республикасы, Алексеевск ш.т.б., Казаков ур., 8 й.<br>ale.6@tatar.ru |
| 7 | Республика матди ярдәм үзәгенең Әлки муниципаль районындагы №7 бүлеге | (84346)<br>2-08-94,<br>2-08-93,<br>2-08-94 | 422870, Татарстан Республикасы, Базарлы Матак ав., Ленин ур., 9 й.<br>alk.7@tatar.ru |
| 8 | Республика матди ярдәм үзәгенең Әлмәт муниципаль районындагы №8 бүлеге | (8553)<br>43-82-52,<br>43-81-96,<br>32-45-47 | 423452, Татарстан Республикасы, Әлмәт ш., Клара Цеткин ур., 54а й.<br>alm.8@tatar.ru |
| 9 | Республика матди ярдәм үзәгенең Апас муниципаль районындагы №9 бүлеге | (84376)<br>2-10-98 | 422350, Татарстан Республикасы, Апас ш.т.б., Шоссе ур., 5 й.<br>apa.9@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | Республика матди ярдәм үзәгенең Арча муниципаль районындагы №10 бүлеге | (84366) 3-13-30, 3-13-51; 3-13-34 | 422000 Татарстан Республикасы, Арча ш., Банк ур., 6В й. ars.10@tatar.ru |
| 11 | Республика матди ярдәм үзәгенең Әтнә муниципаль районындагы №11 бүлеге | (84369) 2-16-55, 2-10-84 | 422750, Татарстан Республикасы, Олы Әтнә ав., Октябрь ур., 9 й. atn.11@tatar.ru |
| 12 | Республика матди ярдәм үзәгенең Баулы муниципаль районындагы №12 бүлеге | (85569) 5-40-40, 5-67-22 | 423930, Татарстан Республикасы, Баулы ш., Җиңү м., 4 й. bav.12@tatar.ru |
| 13 | Республика матди ярдәм үзәгенең Балтач муниципаль районындагы №13бүлеге | (84368) 2-41-93. 2-57-94, 2-64-32 | 422250, Татарстан Республикасы, Балтач ш.т.б., Һади Такташ ур., 3а й. bal.13@tatar.ru |
| 14 | Республика матди ярдәм үзәгенең Бөгелмә муниципаль районындагы №14 бүлеге | (85594) 5-02-95, 5-00-56, 5-02-50 | 423239, Татарстан Республикасы, Бөгелмә ш., Стрелочная ур., 1 й. bug.14@tatar.ru |
| 15 | Республика матди ярдәм үзәгенең Буа муниципаль районындагы №15 бүлеге | (84374) 3-28-09, 3-16-89, 3-41-80 | 422430, Татарстан Республикасы, Буа ш., Ленин ур., 52 й. bui.15@tatar.ru |
| 16 | Республика матди ярдәм үзәгенең Югары Ослан муниципаль районындагы №16 бүлеге | (84379) 2-13-01 | 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан ав., Медицина шәһәрчеге ур. usl.16@tatar.ru |
| 17 | Республика матди ярдәм үзәгенең Биектау муниципаль районындагы №17 бүлеге | (84365) 2-32-51, 2-32-53, 2-32-51 | 422700, Татарстан Республикасы, Биектау ст., Профсоюз ур.,1а й. gor.17@tatar.ru |
| 18 | Республика матди ярдәм үзәгенең Чүпрәле муниципаль районындагы №18 бүлеге | (84375) 2-23-54, 2-30-07, 2-25-80 | 422470, Татарстан Республикасы, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й. dro.18@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 19 | Республика матди ярдәм үзәгенең Алабуга муниципаль районындагы №19 бүлеге:<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Алабуга муниципаль районындагы №19 бүлегенең өстәмә пункты | (85557)<br>7-06-67<br>7-86-91<br>7-54-53 | 423600 Татарстан Республикасы, Алабуга ш., Спас ур., 3 й.;<br><br>423600, Татарстан Республикасы, Алабуга ш., Нефтьчеләр ур., 12 й.<br>ela.19@tatar.ru |
| 20 | Республика матди ярдәм үзәгенең Зәй муниципаль районындагы №20 бүлеге | (85558)<br>3-57-19,<br>7-10-46,<br>7-02-64 | 423520, Татарстан Республикасы, Зәй ш., Рафиков ур., 10 й.<br>zai.20@tatar.ru |
| 21 | Республика матди ярдәм үзәгенең Яшел Үзән муниципаль районындагы №21 бүлеге | (84371)<br>5-80-01,<br>4-22-97,<br>5-79-90 | 420542, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән ш., Карл Маркс ур., 57В й.<br>zel.21@tatar.ru |
| 22 | Республика матди ярдәм үзәгенең Кайбыч муниципаль районындагы №22 бүлеге | (84370)<br>2-11-13,<br>2-10-93,<br>2-14-07 | 422330, Татарстан Республикасы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7й.<br>kai.22@tatar.ru |
| 23 | Республика матди ярдәм үзәгенең Кама Тамагы муниципаль районындагы №23 бүлеге | (84377)<br>2-16-84,<br>2-10-15 | 422820, Татарстан Республикасы, Кама Тамагы ш.т.б., Карл Маркс ур., 2й.<br>kam.23@tatar.ru |
| 24 | Республика матди ярдәм үзәгенең Кукмара муниципаль районындагы №24 бүлеге | (84364)<br>2-76-11,<br>2-83-94,<br>2-61-09. | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш.т.б., Ворошилов ур., 44 й.<br>kuk.24@tatar.ru |
| 25 | Республика матди ярдәм үзәгенең Лаеш муниципаль районындагы №25 бүлеге | (84378)<br>2-54-48 ,<br>2-54-48,<br>2-55-82 | 422610, Татарстан Республикасы, Лаеш ш., Беренче Май ур., 35 й.<br>lai.25@tatar.ru |
| 26 | Республика матди ярдәм үзәгенең Лениногорск муниципаль районындагы №26 бүлеге | (85595)<br>5-47-94,<br>5-84-27,<br>5-55-71,<br>5-08-05 | 423258, Татарстан Республикасы, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 й.<br>len.26@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 27 | Республика матди ярдәм үзәгенең Мамадыш муниципаль районындагы №27 бүлеге | (85563) 3-34-54, 3-12-15, 3-22-83, 3-29-82 | 422190, Татарстан Республикасы, Мамадыш ш., Совет ур., 10 й. mam.27@tatar.ru |
| 28 | Республика матди ярдәм үзәгенең Менделеев муниципаль районындагы №28 бүлеге | (85549) 2-51-99, 2-19-72 | 423650, Татарстан Республикасы, Менделеев ш., Бурмистров ур., 7а й. mnd.28@tatar.ru |
| 29 | Республика матди ярдәм үзәгенең Минзәлә муниципаль районындагы №29 бүлеге | (85555) 3-33-28, 3-18-22, 3-10-50 | 423700, Татарстан Республикасы, Минзәлә ш., Ленин ур., 80 й. mnz.29@tatar.ru |
| 30 | Республика матди ярдәм үзәгенең Мөслим муниципаль районындагы №30 бүлеге | (85556) 2-51-68, 2-38-34 | 423970, Татарстан Республикасы, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й. mus.30@tatar.ru |
| 31 | Республика матди ярдәм үзәгенең Түбән Кама муниципаль районындагы №31 бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Түбән Кама муниципаль районындагы №31 бүлегенең өстәмә пункты | (8555) 45-43-99, 45-43-93 (92,91), 45-44-89, 45-17 01(06) | 423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама ш., Тынычлык пр., 60 й.;<br>423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Кама Аланы ш.т.б., Ильич ур., 2/01 й.<br>niz.31@tatar.ru |
| 32 | Республика матди ярдәм үзәгенең Яңа Чишмә муниципаль районындагы №32 бүлеге | (84348) 2-22-98, 2-27-91, 2-20-30 | 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80 й. nov.32@tatar.ru |
| 33 | Республика матди ярдәм үзәгенең Нурлат муниципаль районындагы №33 бүлеге | (84345) 2-06-56, 2-06-64, 2-06-77, 2-06-86 | 423040, Татарстан Республикасы, Нурлат ш., Пушкин ур., 46 й. nur.33@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 34 | Республика матди ярдәм үзәгенең Питрәч муниципаль районындагы №34 бүлеге | (84367) 3-06-69, 3-00-15 | 422770, Татарстан Республикасы, Питрәч ав., Совет ур., 20 й. pes.34@tatar.ru |
| 35 | Республика матди ярдәм үзәгенең Балык Бистәсе муниципаль районындагы №35 бүлеге | (84361) 2-11-56, 2-20-98 | 442650, Татарстан Республикасы, Балык бистәсе ш.т.б. Завод ур., 6а й. ryb.35@tatar.ru |
| 36 | Республика матди ярдәм үзәгенең Саба муниципаль районындагы №36 бүлеге | (84362) 2-28-18, 2-28-19, 2-28-17 | 422060, Татарстан Республикасы, Байлар Сабасы ш.т.б.,Тукай ур., 87 й. sab.36@tatar.ru |
| 37 | Республика матди ярдәм үзәгенең Сарман муниципаль районындагы №37 бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Сарман муниципаль районындагы №37 бүлегенең өстәмә пункты | (85559) 2-44-05, 2-44-37, 2-57-32 | 423350, Татарстан Республикасы, Сарман ав., Куйбышев ур., 36 й.;<br>423368, Республика Татарстан, Сарман районы, Җәлил ш.т.б., Җиңүнең 30 еллыгы ур., 13 й.<br>sar.37@tatar.ru |
| 38 | Республика матди ярдәм үзәгенең Спас муниципаль районындагы №38 бүлеге | (84347) 3-97-43, 3-00-00 | 422840, Татарстан Республикасы, Болгар ш., Пионер ур., 21 й. spa.38@tatar.ru |
| 39 | Республика матди ярдәм үзәгенең Тәтеш муниципаль районындагы №39 бүлеге | (84373) 2-62-33, 2-62-09, 2-62-33 | 422370, Татарстан Республикасы, Тәтеш ш., Ленин ур., 114 й. tet.39@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 40 | Республика матди ярдәм үзәгенең Тукай муниципаль районындагы №40 бүлеге | (8552) 71-32-00, 70-25-90 | 423802, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Есенин пр., 1 й. tuk.40@tatar.ru |
| 41 | Республика матди ярдәм үзәгенең Теләче муниципаль районындагы №41 бүлеге | (84360) 2-11-37, 2-17-39 | 422080, Татарстан Республикасы, Теләче ав., Большая Нагорная ур., 5 й. tul.41@tatar.ru |
| 42 | Республика матди ярдәм үзәгенең Чирмешән муниципаль районындагы №42 бүлеге | (84396) 2-50-94, 2-29-38, 2-26-34 | 423100, Татарстан Республикасы, Чирмешән ав.,Титов ур., 26 й. chr.42@tatar.ru |
| 43 | Республика матди ярдәм үзәгенең Чистай муниципаль районындагы №43 бүлеге | (84342) 5-12-36, 5-21-60, 5-55-73, 5-33-98 | 422980, Татарстан Республикасы, Чистай ш., Урицкий ур., 45 й. chs.43@tatar.ru |
| 44 | Республика матди ярдәм үзәгенең Ютазы муниципаль районындагы №44 бүлеге | (85593) 2-92-95, 2-87-57, 2-87-57, 2-79-26 | 423950, Татарстан Республикасы, Урыссу ш.т.б., Пушкин ур.,105/1 й. uta.44@tatar.ru |
| 45 | Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Авиатөзелеш районындагы бүлеге | 571-63-71, 570-06-41, 570-79-00 | 420036, Татарстан Республикасы, Казан ш., Тимирязев ур., 8 й. avi.k@tatar.ru |
| 46 | Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Вахитов районындагы бүлеге | 236-90-29, 238-10-55, 236-98-11, 238-23-29 | 420197, Татарстан Республикасы, Казан ш., Вишневский ур., 10 й. vah.k@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 47 | Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Киров районындагы бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Киров районындагы бүлегенең өстәмә пункты | 555-51-80, 554-64-69, 554-47-80 | 420102, Татарстан Республикасы, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5 й.;<br>420078, Татарстан Республикасы, Казан ш., Ильич ур., 21/8 й.<br>kir.k@tatar.ru |
| 48 | Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Мәскәү районындагы бүлеге | 554-77-71, 554-38-43, 554-36-72, 554-03-45, 554-02-16, 554-01-46 | 420102, Татарстан Республикасы, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5 й.<br>mos.k@tatar.ru |
| 49 | Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Яңа Савин районындагы бүлеге | 523-75-81, 523-56-08, 523-75-92, 523-56-42, 523-75-88, 523-75-91 | 420124, Татарстан Республикасы, Казан ш., Хөсәен Ямашев проспекты, 37 й.<br>sav.k@tatar.ru |
| 50 | Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Идел буе районындагы бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Идел буе районындагы бүлегенең өстәмә пункты | 224-04-20, 224-30-61, 224-17-18, 224-35-05, 224-32-01 | 420110, Татарстан Республикасы, Казан ш., Рихард Зорге ур.,39 й.;<br>420054, Татарстан Республикасы, Казан ш., Авангард ур., 74 й.<br>pri.k@tatar.ru |
| 51 | Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Совет районындагы | 272-84-19, 272-22-95, 273-19-95, | 420073, Татарстан Республикасы, Казан ш., Гадел Кутуй ур., 33 й.; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Совет районындагы бүлегенең өстәмә пунктлары | 262-22-47, 239-63-83 | 420075, Татарстан Республикасы, Казан ш., Совет ур., 23 й.;<br>420100, Татарстан Республикасы, Казан ш., Галия Кайбицкая ур., 3 й.;<br>420140, Татарстан Республикасы, Казан ш., Җиңү проспекты, 100 й.<br>sov.k@tatar.ru » |

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-02 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-07 | mtsz@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге начальнигы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларына аудит бүлеге начальнигы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе начальнигы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru”. |